**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки**
**муниципаль районы**
**Аппак авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Аппаковского сельского**
**поселения Алькеевского**
**муниципального района**

Адресы: 422888, ТР, Әлки районы,
Аппак авылы, Тынычлык урамы,1 й.
Тел/Факс 8 (84346) 76443

422888, РТ, Алькеевский район,
с.Аппаково, ул.Мира, д.1
Тел/Факс 8 (84346) 76443

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 7 июне** **17№**

Аппак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге «2021 - 2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен уңайлы икътисадый мохит булдыру максатларында Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Аппак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге 11 номер белән расланган «2021 - 2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Программа паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» графасында «Әлки муниципаль районы халкын эш белән тәэмин итү программасы. Кредит акчалары һәм эшмәкәрләрнең үз акчалары. Җирле бюджет чараларын финанслау» сүзләрен алмаштырырга:
«Җирле бюджет акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| Ел | Җирле бюджет акчалары |
|---|---|
| 2021 | 1 |
| 2022 | 1 |
| 2023 | 1 |
| 2024 | 1 |
| Барлыгы | 4» |

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5 нче бүлек өстәргә:
«5. Программаны финанслау:

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына методик, консультацион-мәгълүмати ярдәм күрсәтү, шулай ук җирле бюджет акчалары исәбеннән финанс, мәгълүмати һәм башка ярдәм алу механизмнары турында мәгълүмат бирү максатларында түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сумнарда)

| Чара исеме | Акча күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен методик кулланмалар, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | 1 | 1 | 1»; |

1.3. Кушымта таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен методик кулланмалар, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

Аппак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: И.Х.Әбҗаббарова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ... АЛЬКЕЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ... ОГРН 1061665001090 ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АППАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1606004238